| | | |
|---|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.12.2021 Казан ш. № 672-195/кс-2021

2022 елга «Восток-Энерго» җитештерү-коммерция фирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга тарифлар билгеләү турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Восток-Энерго» җитештерү-коммерция фирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – «Восток-Энерго» җитештерү-коммерция фирмасы» ҖЧҖ) тарафыннан җибәрелә торган кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга әлеге карар кушымтасы нигезендә календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.
2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2022 елның 1 гыйнварыннан 2022 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.
3. Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Восток-Энерго» җитештерү-коммерция фирмасы» ҖЧҖ ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көннән соңга калмыйча ачарга.
4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын вакытлыча башкаручы С.В.Павлов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
16.12.2021 № 672-195/кс-2021
карарына кушымта

Кайнар су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Восток-Энерго» җитештерү-коммерция фирмасы» ҖЧҖ тарафыннан кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга 2022 елга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Кайнар су белән тәэмин итүче оешма, муниципаль берәмлек исеме | Кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасындагы кайнар суга тариф (ике компонентлы) | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Салкын суга компонент, сум/куб.м | | Җылылык энергиясенә компонент, сум/Гкал | |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр |
| | Чистай муниципаль районы | | | | |
| 1 | «Восток-Энерго» җитештерү-коммерция фирмасы» ҖЧҖ | | | | |
| 1.1. | халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелгән)* | 27,60 | 28,56 | 2033,29 | 2158,30 |
| 1.2. | башка кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 23,00 | 23,80 | 1694,41 | 1798,58 |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын тормышка ашыру максатларында аерып чыгарыла

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул
итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге